| | | |
|---|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2024 № 362-П

Казан

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 нче елның 11 нче ноябрендә гамәлгә кергән 429-П номерлы «Төбәк күләмендә әһәмияткә ия булган мәдәни мирас объектын саклау юнәлешендә эшләр башкару буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү Административ регламентын раслау» хакындагы боерыкка үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 нче елның 11 нче ноябрендә гамәлгә кергән 429-П номерлы «Төбәк күләмендә әһәмияткә ия булган мәдәни мирас объектын саклау юнәлешендә эшләр башкару буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү Административ регламентын раслау» хакындагы боерыкка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуладагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 нче елның 28 нче февралендәге 175 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 нче елның 28 нче февралендәге 175 нче номерлы «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган, төбәк күләмендә әһәмиятле мәдәни мирас объектын саклап калу юнәлешендә эш башкаруга йөкләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентында:

3.5.2.4 пунктының беренче абзацындагы «3.5.3.3» саннарын «3.5.2» саннарына алмаштырырга;

3.6.3 пунктының бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

кушымтаны (белешмә) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Хокук, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эшләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве узарга җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин